Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл Советы

КАРАРЫ

25 февраль 2022 ел № 40

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл Советының 2015 елның 27 февралендәге 126 номерлы карары белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Әлмәт авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1.«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшырырга:

-җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт белән эш итү;

- җирлекнең муниципаль мөлкәте реестрын алып бару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларны билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. « Әлмәт авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен Әлмәт муниципаль районына тапшыру турында» 2020 елның 12 маендагы 135 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Яшьләр бистәсе, Мәктәп урамы, 3 нче йорт; Дербедень

авылы, Совет урамы, 32а нче йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәт авыл җирлеге башлыгы В.И. Газизова